ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

01 11 2019 г. № 688

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә карар бирәм:

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтаның 2.2 пунктының «в» пунктчасында:

«банкротлык,» сүзен «аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алмаштырырга.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов